# Ял сәгатьләрендә

***Сынамышлар***

*Февральнең беренче атнасында тотрыклы һава торышы сакланса, җәй озын яңгырлы булыр.
*Февральдә каен ботагында карлар алка-алка булып асылынып торса, ул елда иген уңар.
*Февраль карга бай, апрель суга бай.
*Февральнең беренче яртысында көннәр суык булса, арыш уңар; җылы булса, тары уңар.
*Февральдә бәс күп булса, агач җимешләре уңар, бал күп булыр.
*Февраль аенда кар күп булса, иртә җәйгә ишарә.
*Февраль ае ахырында кар күп яуса, борчак белән чикләвек уңар.
*Яз суык буласы булса, февральдә төлке эт кебек өрер, улар.
*Әгәр кышның бу ае буранлы икән, августта яңгыр күп, уҗым игене уңачак.
*Кар күп ятса, үлән калын булачак.
*Юлда кар калын, кырда юка булса, иген уңар.
*Көннәр белән бәйле халык сынамышлары:
*2 февраль иртә белән кар - ашлык иртә чәчкәне уңар; кич белән кар яуса - гаҗәп түгел соң чәчкәне уңса.
*3 февраль салкын булса, урак вакытында бик эссе булыр.
*7 февраль көннең беренче яртысы ничек булса, киләсе кышның беренче яртысы шулай булыр.
*8 февраль йолдызлы һәм аяз төн булса, гөмбә уңышы күп булачак.
*9 февраль агачлар бәскә төренсә - тиздән җылытачак.
*12 февраль ай кызарып торса, көчле җил булачак.
*14 февраль күк йолдызлы булса, яз соң килер.
*15 февраль көнне җепшек булса, яз иртә килер һәм җылы булыр
*26 февраль кар эресә, сулар акса, җәй яңгырлы булыр.
*27 февраль җылы һава булса, март аенын башы суык булачак.
*28 февраль боз сөңгеләре озын икән, яз да озын булыр.



## “ГЕНЕРАЛ” САЛАТЫ

***Ингредиентлар :***

- ✓ Пешкән сыер ите - 100 г
- ✓ Бәрәңге-2 данә
- ✓ Кишер-1 шт.
- ✓ Каты сыр-50 г
- ✓ Чөгендер - 1 шт.
- ✓ Майонез-тәме буенча
- ✓ Сарымсак-1 теш
- ✓ Гранат-бизәү өчен

***Тәмле булсын!***



**Газетаны оештыручылар һәм редколлегия әгъзалары:** Камалиева Рәмзия Мәдрәсүл кызы, Нәбиуллина Светлана Рәшит кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы, Мифтахетдинова Фирдания Ансар кызы

**Индекс-** 422020

**Адрес:** ТР, Арча муниципаль районы ,Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 йорт.

Февраль,2025
№ 2




# ЧИШМӘ БАШЫ

2025 ел – Ватанны саклаучылар елы.




## Бәйрәм белән, хөрмәтле Ватанны саклаучылар!



# Изгелек кылырга ашык!

Мәктәбебез коллективы: укучылар, укытучылар, техник хезмәткәрләр, әти-әниләр, #МЫВМЕСТЕ акциясендә катнашуыбызны дәвам итәбез. Без СВО сугышчыларына маскировка челтәрләре үрү өчен махсус тукыманы буй-буй кисеп, әзерлек эшләре алып бардык. Барыбыз бергә зур игелекле эш эшлибез. Аның һәр ячейкасына игелек һәм мәхәббәт үрелә, шуңа күрә мондый саклану теләсә кайсы бронядан да ышанычлырак.

Бүген махсус хәрби операциядә катнашучыларга, якташларыбызга, туганнарыбызга һәм якыннарыбызга ярдәм күрсәтүдә бердәм команда булу бик мөһим. Һәркем зур эшкә үз өлешен кертә һәм бары тик уртак тырышлык белән генә без кемнеңдер гомерен саклап кала алабыз.





23 февраль – календарьда аеруча мөһим дата. Ул- тугрылык, кыюлык ватанпәрвәрлек, батырлык символы. Бу көнне без Бөек Ватан сугышы ветераннары, интернационалист сугышчыларга, “кайнар нокта”ларда булучыларга һәм бүгенге көндә илебезне корал тотып яклаучыларга аеруча зур рәхмәтебезне белдерәбез. Аларны Ватанны сакларга озаткан якыннары алдында башыбызны иябез. Сез – сугышчыларыбызның терәге. Сабырлыгыгыз, рухыгызның ныклыгы өчен сезгә рәхмәт әйтәсебез килә. Бу көнне без бар ир- егетләребезне, ир- ат укытучыларыбызны, ветераннарыбызны һәм буласы солдатларыбызны бәйрәм белән котлыйбыз. Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү ул, туган илен чын күңелдән сөюче граждannарның һәрчак иң югары максаты булды һәм алга таба да шулай булачак, чөнки ата-бабаларыбыздан килгән тәрбия нигезендә ватанпәрвәрлек рухы салынган. Сезгә һәм якыннарыгызга иминлек, ныклы сәламәтлек, рух ныклыгы телибез!

7 нче сыйныф укучылары.






# Конкурста мәктәбебез укучылары

11 февраль көнне Яңа Кырлай мәдәният йортында мәктәп укучылары арасында "Ватанны саклаучыларга багышлана" дип исемләнгән хәрби-патриотик театрлар конкурсы узды.

Конкурста мәктәбебез укучылары "Сугыш балалары" әдәби-музыкаль композициясен тәкъдим итте. Алар үз рольләрен җиренә җиткереп, үзәккә үтәрлек итеп башкардылар.

“...Мылтык тотып, дошманга каршы атакага күтәрелмәделәр, ут эчендә үлем белән күзгә-күз очрашмадылар алар, фронтка китәргә яшьләре житмәде. Сугыш башланганда балалар гына иде бит әле алар! Кәһәр суккан сугыш аларның язмышларына да килеп керде, өмет – хыялларын чәл-пәрәмә китерде, балалык бәхетеннән мәхрүм итте. Ут эченә кермәсәләр дә, сугыш михнәтен ай–һай нык татыдылар алар! Ятимлек ачысын да белделәр, көч житмәслек авыр хезмәттә ватылдылар, ач үлем белән күзгә – күз очраштылар!”






# Батырларның даны мәңгелек




## 8 февраль - яшь герой-антифашистлар көне

Бөек Ватан сугышы яшь совет иле өчен иң авыр сынау була. Немец оккупантлары белән көрәш коточкыч һәм канлы була, ләкин бу үз Ватанын саклауга баскан миллионлаган совет кешеләрен туктатмый. Кешеләр Кызыл Армия сафларына язылып кына калмыйлар, бәлки, партизан отрядлары төзеп, урманнарга да китәләр. Олылар гына түгел, балалар да сугыша. Алар арасында Валя Котик та була.

Бөек Ватан сугышы башланганда, Валяга нибары 11 яшь була. Аларның шәһәрен фашистлар басып ала.

Оккупациядә авыр тормыш башлана. Валя хәтта туганнарыннан да яшереп, төннәрен шәһәр буйлап листовкалар ябыштыра. Озакламый Валя дуслары һәм абыйсы белән партизаннарга ярдәм итә башлый һәм дошманнарга каршы олылар белән беррәттән көрәшә алуын исбатлый.

Башта ул сугыш бара торган тирә-як кырлардан калган коралларын җыя һәм аларны яшерә, немец складларының кайда урнашканын, немец берләшмәләренең кайда торганын һәм аларның санын белә.

1941 елның көзге көннәренең берсендә Валя юл буенда немец гаскәрләренең кайчан күренүен күзәтеп ята - аның бурычы партизан отрядына аларның килеп чыгуы турында кисәтү була.

Ниһаять, пехота төялгән ике йөк машинасы күренә, алардан алда офицер автомобиле бара. Валяга ток суккан кебек була - җиңел машинада йөртүче янында нәфрәтле Фриц Кениг утыра. Малай, бер дә уйлап тормыйча, сикереп тора, үзе белән булган гранатасын машина астына ыргыта да йөгереп китә. Шартлау машина йөртүчене дә, обер - лейтенантны да үтерә, ә автомобиль артыннан барган йөк машинасы туктарга өлгерми һәм аңа килеп бәрелә. Немецлар, паникага бирелеп, оборонага баскан арада, Валяның эзе дә суынган була инде. Бу вакытта аңа нибары 11 яшь була.

1943 ел. Өлкәннәр белән беррәттән ул неа, тимер юлларны миналый һәм хәтта шәхсән үзе телефон кабелен табып, аның буенча турыдан-туры Гитлер ставкасы белән аралаша. Ике тапкыр яралана.

14 яше тулган көнне, 1944 елның 11 февралендә, малай Кызыл Армиянең аның Шепетовкасын азат итүен белә. Соңыннан ул тыныч тормышка кайтырга җыена иде. Ләкин бу сугыш аның өчен соңгысы була: немец пулеметчысы аның корсагына үлем ярасы сала. Һәм 17 февральдә, үзенең туган көненнән соң бер атнадан да кимрәк вакыт узгач, Валя Котик вафат була.

Ул исән чагында "Бөек Ватан сугышы партизаны" медале белән бүләкләнә, ә үлгәннән соң аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә һәм аңа Ленин һәм I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары бирелә. Яшь геройны Шепетовкада җирлиләр.



# Башлангыч сыйныфларда кинодәресләр проекты

Яңа елдан «Россия мәктәпләрендә кинодәресләр» проекты старт алды, ул укучыларның иҗади дөньяга карашын формалаштыруга һәм җәмгыять файдасына социаль әһәмияткә ия эшчәнлеккә этәрүгә юнәлдерелгән.

Проект Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан хупланды һәм тәрбия эше кысаларында кулланырга тәкъдим ителде.

«Россия мәктәпләрендә Кинодәресләр» проекты кысаларында 1-4 сыйныф җитәкчеләре һәм тәрбия буенча директор киңәшчесе укучылар өчен фильмнар карау оештырды:

“Яктылык яугире" (“Воин света”) Е.В. Дубровскаяның шул ук исемдәге хикәясе буенча. Фильм игелек, ярдәмчеллек һәм гаделлек проблемаларына кагылды.

- Режиссер Елена Дубровскаяның “Алла белән кулга кул” (“За руку с Богом"), ул риясызлык сыйфатын ача. Карап чыкканнан соң, балалар игелекле эшләрне риясыз эшләргә дигән бердәм фикергә килделәр.

“Чистакай" (“Чистодей”) - карау алдыннан малайлар исем турында фикер алыштылар. Аның кем булуы турында күп версияләр яңгырады? Фикерләр шундый иде: бу-чисталыкны яратучы кеше; ул-саф һәм якты идеяле кеше. Караудан соң фикер алышу булды, аның барышында балалар үз тәэсирләре белән уртаклаштылар, геройларның гамәлләре һәм фильмда күрсәтелгән хәлнең чынбарлыкка туры килүе турында фикер алыштылар. Балалар теләсә нинди хезмәт кеше өчен бертигез мөһим, шул ук вакытта начар һөнәрләр дә юк дигән нәтиҗә ясады.







# Туган телем - иркә гөлем

20 нче февраль көнне 5 нче сыйныф укучылары “Габдулла Тукай иҗаты иллюстрацияләрдә” дип исемләнгән проет эше якладылар. Шагыйрьнең бик күп әсәрләренә художникларыбыз иллюстрацияләр ясаган.

Илдә нинди генә вакыйгалар булмасын, Тукай иҗатына карата булган кызыксыну беркайчан да кимемәде. Рәсем сәнгатендә Тукай образын гәүдәләндерүдә иң куп көч куйган өлкән буын рәссамнарының берсе - Бакый Урманче. Ул-Татарстанның һәм Россиянең халык рәссамы, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Тукай чордашы.Ул татар сынлы сәнгатенә нигез салучы. Бөек Тукай поэзиясе Урманченың гомер буена бетмәс - төкәнмәс илһам чыганагы булып килә.

Укучылар Г.Тукай әсәрләренә багышланган рәссамнар иҗатын өйрәнделәр, рәссамнарның Тукай иҗатына багышланган эшләренә күзәтү үткәрделәр.







" Туган тел айлыгы " кысаларында китапханәдә "Этот мир многоязычный..."-дип аталган китап күргәзмәсе оештырылды. Күргәзмәгә төрле телләрдә язылган әдәби китаплар куелды. Балаларның сөйләм теле активлыгын үстерү, халык иҗатына , китапка һәм әкиятләргә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан китапханәдә халык әкиятләреннән күргәзмә оештырылды. Озынайтылган көн группа җитәкчесе Закирова Гөлгенә Шәукәт кызы "Халык әкиятләре укыйбыз» дигән темага әңгәмә уздырды.

17 нче февраль көнне татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы безгә, 7 нче класслар өчен туган телгә - ана телебезгә мәхәббәт тәрбияләү, аны саклау, укучыларда тел байлыгын үстерү, туган телнең матурлыгын тоярга өйрәтү максатыннан, "Йолдызлы сәгать" дип исемләнгән интеллектуаль бәйге үткәрде. Кичәдә без, укучылар туган тел турында мәкальләрнең ахырын белдек, сөекле Тукаебыз һәм Арча ягы язучылары турында сорауларга җавап бирдек. Темага карата күңелле кроссвордлар, ребуслар чишелде. Кичә Г.Тукайның "Туган тел" җыры белән тәмамланды.

7 нче сыйныф укучысы Зәйнуллина Гөлзия










# Каюм Насыйриның тууына 200 ел

14 нче февраль -мәгърифәтче, тел галиме, хәзерге татар әдәбияты теленә нигез салучыларның берсе Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулды. Шул уңайдан китапханәдә күргәзмә оештырылды. Аның хезмәтләрен балалар кечкенәдән белергә һәм өйрәнергә тиеш.Мәгърифәтче, галим, фикер иясе, тәрҗемәче, язучы, фольклорчы... Кайсы гына өлкәне алсаң да, Каюм Насыйриның белмәгәне булмагандыр төсле. Вафатына күп еллар узса да, безгә ул әле дә яңа яктан ачыла бара.










Татар халкының танылган мәгърифәтче Каюм Насыйриның тууына 200 ел уңаеннан үткәрелгән Халыкара фәнни-гамәли конференциясе, “Насыйри укулары”нда мәктәбебезнең 9 нчы класс укучысы Галимҗанов Илназ уңышлы чыгыш ясап II дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнде.Укучыбызга киләчәктә дә уңышлар телибез

# Муса Җәлил иҗатын өйрәнәбез.



15нче февраль- бөек татар шагыйре, Советлар Союзы герое Муса Җәлилнең тууына 119 ел булды. Шул уңайдан китапханәдә күргәзмә оештырылды, укучылар аның иҗаты,тормыш юлы белән таныштылар, шигырьләрен укыдылар.



Мәктәбебездә Арча районы профилактика бүлеге җитәкчесе Мухаметзянова Энҗе Газиз кызы булды. Без 6 нчы сыйныф укучылары һәм сыйныф җитәкчебез Рәхимова Р.И. кызы эти- әниләр белән “Юл кагыйдәләрен беләсезме?”исемле КВН уены үткәрдек. Чараның төп максаты – юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәүче гражданнар тәрбияләү, балаларның юлда имгәнүләрен кисәтү. Чара барышында укучылар, ата-аналар үзләренең юлда йөрү буенча белемнәрен күрсәттеләр. Кичә җыр һәм уеннар белән үрелеп барды. Энҗе Газиз кызы чарага югары бәя биреп, безгә бүләкләр өләште.

6 нчы сыйныф укучысы Закиров Ислам.

# Мәктәп тормышы

27 нче февральдә мәктәбебездә волонтёрларның истә калырлык очрашуы булып узды. Беренчел бүлекләрнең егетләре – кызлары үзләренең волонтёрлык эшчәнлеге тәҗрибәсе белән уртаклаштылар, тормышка ашкан проектлары һәм киләчәккә планнары турында фикер алыштылар, төрле мастер класслар үткәрделәр.

Һәр катнашучы үзенең яхшылык һәм җылылыгының өлешен кертеп башкаларга ярдәм итүнең һәм дөньяны яхшыртуның никадәр мөһим икәнен күрсәтте.

10 нчы сыйныф укучысы Сафиуллин Раил





22 февраль көнне мәктәбебездә 2025 ел - Ватанны саклаучылар елын ачу тантанасы булып узды. Хәрби- патриотик кысаларында, Ватанны саклаучылар елына багышланган “Строевой смотр” һәм “Ягез әле, егетләр” спорт ярышлары үткәрелде.

Аңлап, онытмыйча үткәннәрне<br>
Яшәсен дуслык белән халык,<br>
Хәвеф - хәтерләр күрмик,<br>
Һәрвакыт булсын тынычлык!








20 нче февраль көнне 5-7нче класслар өчен татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зарипова Миләүшә Рафис кызы тарафыннан “И мөкатдәс, татар телем” дигән темага класс сәгате узды.Туган телнең матурлыгы, аһәңлеге турында сөйләшеп, телне сакларга кирәклегенә басым ясалды.





21 нче февраль –Халыкара туган тел көне уңаеннан барлык классларда да китапханәче Мифтахетдинова Фирдания Ансар кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучылары Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы, Зарипова Миләүшә Рафис кызы тарафыннан “Тел – милләтнең көзгесе”- дип аталган тәрбия сәгатьләре уздырылды. Туган телгә багышланган шигырьләр укылды, тел турында халыкның мәкаль – әйтемнәре искә төшерелде. Китап күргәзмәсе оештырылды, 5-7нче сыйныфлар арасында туган телгә багышланган шигырь конкурсы үткәрелде.

4 нче укучылары һәм 7 нче сыйныфтан Минуллина Язилә, Зәйнуллина Гөлзия Халыкара туган тел көненә багышланган марафонга кушылдылар.









15 февраль мәшһүр җырчы Илһам Шакировның туган көне. Шул уңайдан музыка укытучысы Шарафетдинова Гөлзада 4 – 7 нче сыйныф укучыларына “Илһам Шакиров – бөек җырчы” дип исемләнгән тәрбия сәгате уздырды.Укучылар Илһам Шакировның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштылар

# Иҗат чишмәсе



***Сугыш чоры баласы, ветеран укытучыбыз Галяветдинова Венера Рәфгать кызы иҗаты***

**Китмибез**

(Тукайга иярep)

Китмибез без, ник китик соң
Кесәдә юк миллион.
Анда да шул, монда да шул
Һәркайда бар шпион.

Китмибез булгач ,китмибез,
Йөрмибез эзләп рәхәт.
Артыннан иярeп йөри
Син күрәсе ул михнәт.

Монда тудык ,монда үстек
Мондадыр безнең әҗәл.
Туда-сюда чыгып китеп
Кайта алмаучылар бигрәк җәл.

Без юләрме? Илдән китсәк,
Рәхәт кайсы дөньяда?
Лучше булса китегез сез
Туда сами господа!

Хөр мәмләкәт – хөр Русия!
Без бит сиңа береккән.
Безнең Ватан җирдә – үрнәк,
Тынычлыкка көчле терәк.



**Безнең Тукай**

Туган көнең нинди матур,
Кырлайда зур тантана .
Нәни Апушны сагынып,
Килә дуслар кунакка.

Килә төрек , әзербайҗан
Килә Мәскәү һәм Казан.
Авылыбызны яңгыратып,
Ишетелә моңлы азан.

Гаскәр кеби тезелеп тора,
Без утырткан каеннар.
Күлләрендә чумып уйный
Зифа матур аккошлар.

Тукай,синең чишмәкәйнең
Суы һаман кипмәгән.
Бардыр әле тагын берәү
Тәмле суын эчмәгән.

Күрсә иде бу хозурны,
Хәйләкәр таз малаең.
Кәҗә белән сарык асрап,
Гомер иткән агаең.

Һәркем өчен якын хәзер
Тукайның Казан арты
Аңа мәдхия җырлыйлар
Барлык илебез халкы.



# «Җиңү юллары»

Сталинград сугышында немец-фашист гаскәрләрен совет гаскәрләре тар-мар иткән көн алдыннан мәктәбебездә «Җиңү юллары»дигән виртуаль экскурсия үткәрелде. Аны тәрбия эше буенча директор киңәшчесе И.М. Шакирова алып барды.

Чара башында яшь армиячеләр, Җиңү волонтерлары егетләре Сталинград сугышы барышы белән таныштырдылар. Чара барышында укучылар Бөек Ватан сугышы елларында халкыбызның батырлыгы һәм ныклыгы символына әверелгән «Сталинград сугышы» музей-панорамасы һәм Мамай курганы кебек әһәмиятле урыннарда булдылар. Сталинград өчен сугыш Бөек Ватан сугышының борылыш мизгелләренең берсе булды һәм Россия тарихында төп рольне уйнады. Мамай Курганы, истәлекле урын буларак, Ватан өчен көрәшкән совет солдатларының батырлыгын һәм каһарманлыгын гәүдәләндерә. Экскурсиядә катнашучылар Сталинград оборонасы тарихы һәм Кызыл Армия солдатларының батырлыклары белән танышып, героик үткәннәр атмосферасына чуму өчен уникаль мөмкинлек алдылар. Мамай Курганы-һәйкәл генә түгел, батырлык һәм ныклык символы да. Виртуаль сәяхәт вакытында укучылар " Ватан-Ана чакыра!"һәм мемориалның башка элементларының шәһәрне саклаучыларның батырлыгы турындагы истәлекне мәңгеләштерүдә зур роль уйнавын аңладылар. Экскурсия җанлы кайтаваз уятты, герой-шәһәр Волгоград тарихы белән кызыксынуны үстерүгә һәм патриотизм тәрбияләүгә ярдәм итте.





